**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район,
село Атабаево,ул.Молодежная , д.1
тел: 8(84378)-4-87-41
факс: 8(84378)4-87-41

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
ул.Яшьлэр урамы, 1нче йорт
тел: 8(84378)-4-87-41
факс: 8(84378)-4-87-41

2024елның «01» феврале 178 номер

***К А Р А Р***

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында 2023 елның 23ноябрендәге 158 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советының 2023 елның 23 ноябрендәге 158 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

32 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

" Муниципаль хезмәте турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә озак еллар хезмәт иткән өчен пенсияләрне билгеләү һәм түләү турында мәгълүмат "Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа"дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүматны социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада урнаштыру (алу) 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт социаль ярдәме турында» гы Федераль закон нигезендә башкарыла.»

2. Әлеге карарны Атабай авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советы рәисе** **Хәлилова Л.Р.**